**Татарстан Республикасы**

**Әлки муниципаль районы**
**Базарлы Матак**
**авыл җирлеге Советы**

**Республика Татарстан**
**Алькеевский**
**муниципальный район**
**Совет Базарно - Матакского**
**сельского поселения**

**Адресы: 422870**
**Базарлы Матак авылы**
**Крайнов ур. 94**
**Тел: 2-00-71, 2-15-62**

**Адрес: 422870**
**с. Базарные Матаки**
**ул. Крайнова д. 94**
**тел: 2-00-71, 2-15-62**

**РЕШЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2023 елның 23 октябре 102№

2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 ст., 85 ст. 8 п. 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә 2023 елга Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районына Базарлы Матак авыл җирлеге караган милекне хосусыйлаштыру планын расларга.

2. 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашыру максатларында Әлки муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми www.torgi.gov.ru сайтында бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Базарлы Матак авыл җирлеге Советының 2020 елның 10 июнендәге 3 номерлы карарын «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Базарлы Матак авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2020 елның 10 июнендәге 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне ТР Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Базарлы Матак авыл җирлеге башлыгы: А.Ф.Никошин

1 нче Кушымта

**2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы « Базарлы Матак авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2023 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2023 елда муниципаль казнадагы һәм Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар карамагында булмаган муниципаль милек хосусыйлаштырыла.

2.2.Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Милекнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чарасы Җиңел машина FIAT DOBL0223AXP1A идентификацион номеры (VIN) XU3223000AZ306526 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов урамы, 94 йорт | 2010 | 4 чирек |
| 2 | Автотранспорт чарасы Җиңел машина AUDI A6 идентификацион номеры (VIN) WAU7774F8BN008365 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов урамы, 94 йорт | 2010 | 4 чирек |

## 3 нче бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.